СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2024 елның «27» мартыннан № 43-330

2023 елда «Россия Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районы буенча бүлегенең эше, шул исәптән Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм 2024 елга бурычлар турында

Россия Эчке эшләр министрлыгының Яңа Чишмә районы буенча бүлеге башлыгы А.Н.Митрясовның 2023 елда «Россия Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районы буенча бүлегенең эше, шул исәптән Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм 2024 елга бурычлар турында мәгълүматын тыңлаганнан соң, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Россия Эчке эшләр министрлыгының Яңа Чишмә районы буенча бүлеге башлыгы А.Н.Митрясовның 2023 елда «Россия Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы Яңа Чишмә районы буенча бүлегенең эше, шул исәптән Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә җәмәгать тәртибен тәэмин итү һәм 2024 елга бурычлар турында мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Тәкъдим итәргә:

2.1. Россия ЭЭМ Яңа Чишмә районы буенча бүлегенә:

- районда предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар белән берлектә ирекле халык дружиналары эшчәнлеген оештыру буенча эшне көчәйтергә, полициянең участок уполномоченныйлары эшен яхшыртырга;

- иҗтимагый берләшмәләр әгъзалары белән берлектә үзләрен асоциаль тотучы затларны ачыклау һәм алар белән индивидуаль-профилактик эш үткәрү буенча уртак эшне дәвам итәргә;

- район территориясендә яшәүче, әмма яшәү урыны буенча теркәлмәгән һәм гражданлыгы булмаган затлар белән эшне көчәйтергә;

- милли проектларны (программаларны) тормышка ашыру өлкәсендә бюджет акчаларын урлау фактларын ачыклау һәм булдырмау, дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләрне сатып

алганда явызларча файдалануга каршы тору буенча эшнең нәтиҗәлелеген арттырырга;

- җинаять эшчәнлегенә җәлеп итүгә каршы тору максатыннан балигъ булмаганнар арасында хокук бозуларны профилактикалау буенча эшне көчәйтергә;

- юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүгә, шул исәптән балалар өчен юл-транспорт имгәнүләрен профилактикалауга юнәлдерелгән торган чараларның нәтиҗәлелеген арттырырга;

- мәгълүмати технологияләр кулланып кылынган җинаятьләрне профилактикалау механизмнарын камилләштерү буенча чаралар күрергә;

- җәмәгать урыннарында һәм торак пунктларның урамнарында административ хокук бозуларны ачыклау һәм булдырмау буенча эш алып барырга.

2.2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетына:

- җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә ярдәм күрсәтү, шулай ук халык дружиналары эшчәнлеге өчен шартлар тудыру эшен дәвам итәргә.

- гражданнар күпләп була торган объектларны террорчылыктан яклау максатыннан, объектларны сакчылык-кисәтү сигнализациясе белән тәэмин итү һәм шәхси сак оешмасы пультына чыгучы кисәтү сигнализациясе төймәсе белән җиһазландыру, видеокүзәтү һәм әлеге объектларны паспортлаштыру эшен дәвам итәргә. Район территориясендә яңа объектлар ачылганда (кибетләр, оешмалар һ. б.), әлеге объектларны тикшерү үткәрү буенча полиция бүлеге белән килешергә;

- «Имин шәһәр» аппарат-программа комплексын гамәлгә ашыру кысаларында видеокүзәтү системаларын үстерүне дәвам итәргә;

- Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә җәмәгать тәртибен һәм гражданнар куркынычсызлыгын саклауны оештыру буенча хокук саклау органнары белән хезмәттәшлекне активлаштырырга.

- административ хокук бозуларны ачыклау һәм тиешле протоколлар төзү буенча вазыйфаи затлар эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру;

- хокук саклау юнәлешендәге муниципаль программаларны гамәлгә ашыруны һәм вакытында финанслауны, шулай ук аларны актуальләштерүне тәэмин итәргә.

2.3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлегенә, мәгариф бүлегенә:

- кичке вакытта яшьләрнең ялын оештыруга һәм хокук бозуларны иртә профилактикалауга аерым игътибар биреп, укучылар һәм яшьләр арасында хокук бозуларны профилактикалау эшен активлаштырырга.

2.4. Нинди милек формаларында булуларына карамастан, барлык предприятие һәм оешма җитәкчеләренә тәкъдим итәргә:

- мөлкәтнең һәм матди кыйммәтләрнең сакланышын тәэмин итү буенча эшне көчәйтергә;

- товар-матди кыйммәтләрне саклау объектларын техник яктан ныгыту, шул исәптән яхшы сыйфатлы видеокүзәтү камераларын урнаштыру буенча да, чаралар күрергә.

2.5. Авыл җирлекләре башлыкларына:

- хокук бозуларны профилактикалау буенча хокук саклау юнәлешендәге ижтимагый берләшмәләрнең эшен активлаштырырга;

- норматив хокукый документларны районның рәсми сайтында вакытында урнаштыруны тәэмин итәргә, шулай ук аны актуальләштерү һәм тиешле үзгәрешләр кертү максатында урнаштырылган мәгълүматка мониторинг ясауны тәэмин итәргә.

2.6. Россия Эчке эшләр министрлыгының Яңа Чишмә районы буенча бүлегенә авыл җирлекләре Башлыклары белән берлектә:

- өйдә эшләнгән спиртлы продукцияне һәм алкогольле продукцияне законсыз сатуны ачыклау буенча җинаять һәм хокук бозуларны ачыклау эшен активлаштырырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов